# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Турай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

КАРАР

14 ноябрь 2025 ел № 16

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пункты гражданнар җыены карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәрен, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнарны үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

2.1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу; МТЗ-82.1 тракторы өчен чүмечле КУН сатып алу)

2.2) Турай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү.))

2.3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Турай торак пунктының Крайняя, Тынычлык, Окольная, Совет урамнары буенча юл өслегендәге чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу; вак таштан соң юл өслеген тигезләү ( эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).)

2.4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

2.5) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән

чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү)
2.6) Үзара салым акчаларының узган еллардагы калдыкларын юлларны кардан чистартуга тотарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Турай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге башлыгы А.Т. Нуриев